**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Карары**
**өченче чакырылыш утыз өченче утырышы**

**06 февраль 2019 ел** **№ 108** **Әбде авылы**

**Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 02 мартындагы 25 санлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273 санлы Федераль законга, Татарстан Республикасының «Муниципаль хезмәт турында»гы 2013 елның 25 июнендәге 50 санлы законына туры китереп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советы, Теләче районы прокурорының 2018 елның 20 декабрендәге 02-08-02-2018 санлы гаризасын карап,

КАРАР БИРДЕ:

1.Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советының «Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) раслау турында»гы 09.06.2016 елның 20 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 28нче Бүлекнең 1 пункты 2 подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы вәкил аша шөгыльләнү, коммерция оешмалары яки коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш); профсоюз органы белән идарә итүдә түләүсез катнашу, шул исәптән җирле үзидарә органында оешкан беренчел профсоюз оешмасының сайланып куелган органы белән дә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында; башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативлары, күчемсез милек ияләре ширкәте съездында (конференциядә); күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән һәм профсоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында) бер генә кеше

идарә итә торган башкарма орган сыйфатында яки эш бирүченең рөхсәте белән аларның идарә итү коллегиаль органнары составына керү, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә), учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен чагылдырудан тыш, муниципаль берәмлек исеменнән оешмаучредителе вәкаләтләрен башкару яки муниципаль милек булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлеше) белән идарә итүне билгеләүче муниципаль хокукый актларына нигезләнеп; федераль законнар белән каралган башка очраклардатүләүсез идарә итүдә катнашу.

Муниципаль вазифаларны алыштыручы һәм вәкаләтләрен даими башкаручы затлар коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән, түбәндә санап кителгән очраклардан тыш, идарә итүдә катнашырга хокуклы түгел:

а) Россия Федерациясе субъектлары муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партия, тиешле тәртиптә теркәлгән профсоюз белән идарә итү, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гаражкооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача, кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек ширкәтләре съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашу;

в) учредителе (акционеры, катнашучысы) Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты булган оешманың идарә итү органнарында яки ревизия комиссиясендә Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъектлары исеменнән оешманың учредителе вәкаләтләрен башкару яисә федераль милек яки Россия Федерациясе субъекты милке булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив-хокукый актларына яки Россия Федерациясе субъектлары норматив-хокукый актларына туры китереп,Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъектлары мәнфәгатьләрен түләүсез чагылдыру;

г) учредителе (акционеры яки катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында яки ревизия комиссиясендә,муниципаль хокукый актларга туры китереп,оешма учредителе исеменнән муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен чагылдыру;

д) федераль законнар белән каралган башка очракларда.

Муниципаль вазифаларны алыштыручылар, әлеге вазифаларны башкарган чорда, эш бирүче (җитәкче) вәкилләре буларак, дәүләт органында яки муниципаль органда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатыннан, әлеге органнарның сайланып куелучы профсоюз органында дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен чагылдыра алмый»

1.2. 29нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт белән тулыландырырга: «5. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатыннан, җирле үзидарәнен элеге

органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының сайланып куелучы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен чагылдыра алмый.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Әбде авыл җирлеге башлыгы: Н.М.Домолазов